**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 31 июль № 555

г. Казань

«Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт автоном учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау өлкәсе инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт автоном учреждениесенең (алга таба - «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ) гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 420075, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дербышка поселогы, Прибольничная урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ бетерү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

14 көн эчендә:

«Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ бетерү комиссиясе составын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ бетерү тәртибен һәм вакытын билгеләргә;

«Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ бетерү турында карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә теркәүче органга Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ бетерү процессында булу турында белешмәләр тапшырырга;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бетерелүче «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУга оператив идарә итү хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез һәм аеручы кыйммәтлесен, киләчәктә

файдалану турында тәкъдимнәр (күрсәтелгән мөлкәтнең исемлеген теркәп) тапшырырга;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә бетерү нәтиҗәсендә эштән чыгарылган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә, шулай ук «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ бетерү буенча законда каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 60 көн эчендә законда билгеләнгән тәртиптә элек «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУга беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы биргән мөлкәт исемлеге нигезендә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2015 елга һәм 2016 һәм 2017 елларның планлаштырылган чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджеты исемлегенә үзгәрешләр кертергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\555.doc